ҖОМГА
15
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 12 (6734)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН өлкә һәм КАЗАН шәһәр КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ КОМСОМОЛЕЦЛАРЫНА ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕНӘ ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ КОТЛАУ ТЕЛЕГРАММАСЫ УҢАЕ БЕЛӘН РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ ҮТКӘН РАДИОМИТИНГТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ

МӨРӘҖӘГАТЕ

ОРДЕНЛЫ ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК КОМСОМОЛЕЦЛАРЫНА ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕНӘ, ПИОНЕРЛАРЫНА ҺӘМ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА!

Иптәшләр!

Күп айлар буена совет халкы һәм аның героик Кызыл Армиясе немец-фашист басып алучыларга каршы үлем сугышы алып баралар.

Кабахәт дошман, безнең җиребезгә хыянәтчел төстә һөҗүм итеп, кыска вакыт эчендә Совет дәүләтен юк итәргә, безнең кешеләребезне коллар итеп әвереләдерергә теләгән иде. Барып чыкмады! Иптәш Сталинның чакыруы буенча совет кешеләре, кечкенәсеннән алып зурысына кадәр, Ватаныбызны, аның намусын һәм бәйсезлеген нык торып сакларга бастылар.

Безнең меңнәрчә ир һәм кыз туганнарыбыз, кулларына корал тотып, кабахәт дошманны тар-мар итү өчен фронтка киттеләр. Немец юлбасарларына каршы атакага баручы совет сугышчыларының йөрәкләре изге нәфрәт ялкыны белән тулган. Җимерелгән шәһәрләр өчен, яндырылган авыллар өчен, немецлар тарафыннан газапланган балалар һәм картлар өчен, мыскыл ителгән кызлар һәм хатыннар өчен—боларның бөтенесе өчен дә безнең сугышчылар дошманнан үч алалар. Гитлерчы шакшылар бөтенесе өчен дә җәза алалар һәм алырлар.

Безнең тылда калган егетләр һәм кызлар җиңүне яулап алу эшенә бөтен көчләрен, бөтен энергияләрен бирәләр. Алар заводларда һәм фабрикаларда, колхозларда һәм совхозларда, институтларда һәм мәктәпләрдә сугышчан корал коялар, аруны белми эшлиләр.

Иптәш Сталинның доклады һәм приказы белән рухланган совет халкы зур патриотик эшне—һөҗүм итүче Кызыл Армия өчен танк колонналары һәм самолет эскадрильяләре төзелешенә средство җыю эшен башлады. Бу мактаулы эшкә орденлы Татарстанның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары йөз миллион сум акча керттеләр. Бу бөтен халыкны чолгап алган куәтле хәрәкәтне яшьләр башлап җибәрделәр.

Саба районы комсомол оешмасында «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү инициативасы туды. Сабалылардан үрнәк алып, республиканың яшь колхозчылары сугышчан машиналар төзелешенә кырык биш миллион сум акча керттеләр. Азнакай районы, Сәпәй мәктәбе укучылары отлично өлгереш һәм дисциплина өчен көрәшеп, анабыз Ватанга һәм данлы Кызыл Армиягә ярдәм итәргә теләп, республикада беренче булып «Татарстан пионеры» исемендәге самолетлар эскадрильясе төзелешенә акча җыя башладылар һәм биш мең сум акча җыеп тапшырдылар да инде.

Кызыл Армия үзенең бөек полководецы иптәш Сталин сүзләре белән Татарстан республикасының колхозчы крестьяннарына, татар яшьләренә рәхмәт белдерде.

Фронтовиклар, танклар төзелешенә өч йөз мең сум акча җыйган Тәмте районы яшьләренә рәхмәт әйтәләр. Фронтовиклар, Кызыл Армия өчен азык фонды төзүгә актив катнашып, ун ике мең биш йөз алтмыш алты пот ашлык җыярга ярдәм иткән Октябрь районы яшьләренә рәхмәт әйтәләр.

Иптәш Сталинның комсомолецларга һәм яшьләргә җибәргән котлавы һәм рәхмәте шәһәрләрдә һәм авылларда куәтле чакыру булып, дошманны тизрәк тар-мар итү эшенә бөтен энергияне, бөтен көчне һәм средствоны бирергә чакыру булып яңгырый.

Яшь эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар!

Социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерик, Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа, куәтле хезмәт күтәренкелеге белән билгеләп үтик.

Фронтовикларга сугышчан бүләкләр—кораллар-ның, припасларның, сугыш кирәк-яракларының яңадан-яңа эшелоннарын бирик.

Яшь колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар!

Сөекле юлбашчыбызга данлы эшләребез белән—фронтны икмәк, ит һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү турында тагын да күбрәк кайгыртуыбыз белән җавап бирик. Колхозларның һәм совхозларның барлык төр тапшыруларын буенча дәүләт алдындагы йөкләмәләрен тизрәк үтәүләре өчен, язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнү өчен, югары хәрби уңыш алу өчен, терлекчелекнең продуктлылыгын арттыру өчен большевикларча көрәшик. Ил һәм фронт өчен куәтле азык фондлары төзик.

Татарстан республикасының комсомолецлары һәм комсомолкалары, егетләр һәм кызлар, пионерлар һәм мәктәп балалары!

Эшче Крестьян Кызыл Армиясенең 25 еллыгы якынлаша. Бу данлыклы көнгә фронтка бәйрәм бүләкләре җибәрик.

Анабыз Ватанга, героик Кызыл Армиягә яңа бүләк әзерлик—«Татарстан комсомолы» һәм «Татарстан пионеры» исемендәге самолетлар эскадрильяләре төзелешенә акча җыюны оештырыйк. Кеше ашаучы фашистларны тар-мар итүне тизләтү өчен бер нәрсәбезне дә кызганмыйк.

Яшәсен безнең җиңүебез!
Яшәсен героик Кызыл Армия!
Яшәсен даһи полководец, атабыз һәм остазыбыз, совет яшьләренең иң якын дусты бөек Сталин!

ВЛАДИВОСТОК, ВКП(б) ның БУДЕННЫЙ РАЙКОМЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ОСИПОВКА

Кызыл Армия турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен Буденный районы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

АЗЕРБАЙҖАН ССР, ЛЕНКОРАН РАЙОНЫ, МАМУСТ АВЫЛЫ «КОМСОМОЛ» КОЛХОЗЫ КОЛХОЗЧЫСЫ ФАРАБАН МАНАФ КЫЗЫ КӘРИМОВА ИПТӘШКӘ

Кызыл Армия турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәт Сезгә, иптәш Кәримова. Минем сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

КАЗАХСТАН ССР, ЛУГОВОЕ, ПАРТИЯНЕҢ ЛУГОВОЕ РАЙКОМЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ИТКИНГА

«Казахстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 2.107.000 сум акча җыйган Луговое районы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ, ПАЧЕЛМСКИЙ РАЙОНЫ, «ЛУЧ ОКТЯБРЯ» КОЛХОЗЫ КОЛХОЗЧЫСЫ ГРИГОРИЙ ЯКОВЛЕВИЧ КУЗНЕЦОВ ИПТӘШКӘ

Кызыл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәт Сезгә, Григорий Яковлевич. Минем сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ВКП(б) НЫҢ СМОЛЕНСК ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ПОПОВКА

Смоленск өлкәсенең немец оккупантлардан азат ителгән районнарының, шулай ук дошман тарафыннан вакытлыча оккупацияләнгән районнарының, илнең оборонасы фондына, шул исәптән «Смоленск партизаны» исемле танклар колоннасы төзүгә 14.952.980 сум акча һәм 6.000 пот ашлык керткән хезмәт ияләренә минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Яшьләрнең республика күләмендәге радиомитингысы

12 нче январьда, иптәш Сталинның совет яшьләренә биргән җавабына багышлап республика күләмендә радиомитинг үткәрелде. Митингны ВЛКСМ Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация буенча секретаре иптәш Юскаева ачты. Ул кереш сүзе сөйләде, ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре иптәш Михайловнын хатын һәм иптәш Сталинның бу хатка җавабын укып чыкты.

Беренче сүз Н-че завод стахановчысы комсомолец Афзал Батталовка бирелде.

— Иптәш Сталинның җавабы безне хезмәт фронтында яңа уңышларга рухландыра. Кызыл Армиягә ярдәмне торган саен көчәйтергә чакыра,—ди ул һәм завод яшьләренең патриотик күтәрелеше турында, фронтка ярдәмне көчәйтергә теләп, «Татарстан комсомолы» исемендәге сугышчан самолетлар эскадрильясе төзелешенә хезмәт хакларының 5 процентын кертүләре, ә үзенең 10 процент бирүе турында сөйли.

Микрофон алдына Арча районының «Спартак № 1» колхозы стахановчысы комсомолка Мөршидә Галимова чыга.

— Мин Ватаным алдындагы, Кызыл Армия алдындагы бурычымны аңлыйм,—ди ул. Шуның өчен колхоз производствосында бөтен көчемне биреп эшлим, фронтка кулымнан килгән кадәр ярдәм итәргә тырышам. Мин танклар колоннасы төзелешенә 1.100 сум акча керттем, оборона фондына 6 пот ашлык тапшырдым.

Яшь патриотларның ялкынлы сүзләре эфирга тарала. Микрофон алдына бер-бер артлы яшь эшчеләр, колхозчылар, студентлар, укучылар чыгалар. Химико-технология институты студенткасы, Сталин исемендәге стипендияне алучы иптәш Темкина институтта «Совет студенты» һәм «Совет галиме» исемле самолетлар эскадрильяләре төзелешенә акча җыюның зур активлык белән баруы турында сөйли.

Н-че заводлардан стахановчылар Гришаев һәм Галләмов иптәшләр дә, 12 нче мәктәпнең Чапаев исемендәге пионер дружинасы вожатые Идрисова да, Юдино районы «Серго» колхозы хисапчысы Данилова да, ВЛКСМ ның Арча райкомы секретаре иптәш Филиппова да, яшьләрнең патриотик күтәрелешләре, безнең җиңүебез өчен барысын да эшләргә әзер торулары турында сөйләделәр.

Шефтагы авиаполк вәкиле Еренкәв чыкты. Ул Татарстан республикасы яшьләренә мөрәҗәгать итеп болай диде:

— Сезнең узган ел җыйган акчаларыгызга төзелгән самолетлар безнең полкка тапшырылды. Хәзер бу самолетлар Ватан сугышы фронтларында сугышчан операцияләрне уңышлы алып баралар. Без сезне фронтка ярдәмне тагын да көчәйтергә, сугышчан машиналарны тагын да күбрәк бирергә чакырабыз.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш Шәфиков юлбашчының рәхмәтенә җавап итеп, республика яшьләренең үз постларында армый-талмый эшләячәкләрен, фронт таләп иткәннең барысын да үтәячәкләрен белдерә.

Радиомитингта республиканың барлык комсомолецларына һәм яшьләренә мөрәҗәгать укыла:



Полковник Петров частенда фронт өчен резерв әзерләү эше яхшы куелган. Рәсемдә: Советлар Союзы Герое подполковник Матруничик частеның очучылар составы группасы самолет моторын өйрәнәләр. Занятиене капитан Леушев алып бара.

Б. Невзоров фотосы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

14 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

14 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар поселогында безнең штурм отрядлары дошманны 27 ДЗОТ тан һәм блиндаждан бәреп чыгардылар. Немецлар берничә тапкыр контратака ясап карадылар, ләкин чигенделәр.

Сталинград районында совет очучылары немецларның бер аэродромына һөҗүм итеп, дошманның 5 самолетын юк иттеләр һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар. Шуның өстенә һава сугышларында немецларның 7 самолеты атып төшерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, дошманның ныклы каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть немецларның танклар белән көчәйтелгән бер батальон пехотасын тар-мар итте. 400 гә якын гитлерчы, 6 танк һәм 3 орудие юк ителде. Икенче бер участокта безнең частьлар кискен удар белән дошманның оборонасын өзделәр һәм, уңышны җәелдереп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Гитлерчылар зур югалтуларга дучар ителделәр. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Великие Лукидан төньяк-көнбатыштагы районда дошман пехотасының һәм танкларының контратакасы кире кайтарылды. Сугыш кырында дошманның 200 дән артык үле гәүдәләре һәм яндырылган 8 танкысы калды. Икенче бер участокта безнең артиллерия уты белән немецларның җыелып тора торган пехотасы таркатылды һәм бер өлеше юк ителде, дошманның дистәләрчә ДЗОТ лары һәм блиндажлары җимертелде.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть танкистлары бик каты сугышта дошманның бер пехота частен тар-мар иттеләр. 19 орудие, 53 автомашина, 3 трактор, шулай ук запас частьлар һәм сугыш припаслары складлары кулга төшерелде. Концентрация лагеренда булган совет гражданнарыннан һәм пленный кызылармеецлардан зур бер группа, фашистлар пленлыгыннан азат ителде. Икенче бер участокта безнең артиллерия уты белән дошманның 6 танкысы зарарланды һәм яндырылды, җыелып тора торган бик күп автомашиналары һәм пехотасы таркатылды.

* * *

Барановичи өлкәсендә хәрәкәт итүче отрядның бер группа партизаннары бер ай эчендә немецларның 5 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Һәлакәт нәтиҗәсендә 5 паровоз, 8 платформа, немец солдатлары төялгән 25 вагон, сугыш припаслары һәм техника төялгән 39 вагон җимерелгән.

* * *

Түбәндә Калмык АССР ның башкаласы булган Элиста шәһәрендә немец фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецлар Элистаны алганнан соң берничә көн үткәч шәһәргә гестапочылар бандалары килеп керде һәм алар совет гражданнарын җәзаларга керештеләр. Бандитлар Калмык АССР ның атказанган врачы Колесниковны, эшче һәм хезмәткәрләрдән Калымовны, Касеевны, Рыбаловны, Лиджиевны, Айбашевны, Масловны, Худжуровны, Чибиновны, Убушаевны, Федоровны һәм башкаларны кулга алдылар. Немецлар кулга алынучыларны коточкыч төстә газапладылар. Гитлерчы бандитлар врач Колесниковка камчы белән 50 тапкыр суктылар, ә соңыннан бөтенләй чишендереп салкын подвалга ташладылар. Икенче көнне аны машинага утыртып шәһәр читенә алып киттеләр һәм шунда атып үтерделәр. Шулай ук фашист ерткычлар врач педиатр Анна Драновны, потребсоюз бухгалтеры Виноградовны, итекче Иван Василенконы һәм башка күп кешеләрне аттылар. Җан кыючы һәм кан эчүче немецлар кешеләрне терелэй җиргә күмделәр. Тулы булмаган саннарга карaганда, гитлерчылар шәһәр халкыннан 800 дән артык кешене үтергәннәр. Немец басып алучылар шәһәрдә һәм тирә-як авылларда торучы кешеләрнең азыкларын, терлекләрен һәм башка әйберләрен талап алдылар. Алар культура учреждениеләрен пычраттылар һәм педагогия институтын, мәгариф йортын ат абзарына әйләндерделәр. Совет хөкүмәте Элистада предприятиеләр, бик яхшы җәмәгать бинаралы, клублар, уку йортлары, мәктәпләр, больницалар салдырган иде. Немецлар чигенүдән ике көн элек Калмык республикасының башкаласын юк итәргә керештеләр. Хөкүмәт йорты, Наркомзем һәм Наркомфин бинаралы, электр станциясе, икмәк пекарнясы, водопрозод, матбугат йорты, почта һәм телеграф, больницалар, бала тудыру йорты, 3 ашханә һәм башка төрле җәмәгать бинаралы һәм торак йортлар җимертелде һәм яндырылды. Фашист ерткычларның һәм көчләүчеләрнең барлык эшләгән җинаятьләре өчен тулысынча җәзаланачаклары сәгате ерак түгел, лекин калмык халкы ышана». Актка кул куйдылар: хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты председателе урынбасары А. Багдыков, 5 нче номерлы тулы булмаган урта мәктәп укытучылары П. Несенова, Н. Корниленко, кирпеч заводы эшчеләре Сакалов, Герасимов, Володарский исемендәге авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы А. Коробейнико, потребсоюз бухгалтеры К. Цветков, шәһәр коммуна хуҗалыгы эшчесе Г. Торбенко, типография эшчесе С. Голубев.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

БЕЗНЕҢ КАЙБЕР ТӘҖРИБӘЛӘР

«Красное Прикамье» колхозы янындагы агитколлектив оештырылганга елдан артык кына вакыт үтте әле. Ләкин агитколлективның эшендә үрнәк булырлык моментлар байтак инде.

Бу коллектив колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны Совет Информбюросы белдерүләре, Ватан сугышы эпизодлары, якташларыбызның батырлыклары һәм партия, хөкүмәт карарлары белән таныштыра. Хәзерге көндә алда торган бурычларны үтәүгә, дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәүгә колхозчылар массасын туплый.

Агитколлектив (җитәкчесе иптәш Каталина) колхоз активы арасында системалы рәвештә эш алып бара. Мәсәлән, стахановчылар өчен түгәрәк оештырылган иде. Бу түгәрәк билгеләнгән программа буенча эшен тәмамлады инде. Хәзер шул ук активлар өчен агымдагы политика түгәрәге эшләп килә.

Бу түгәрәк активның политик һәм производство белемен күтәрүгә зур ярдәм итә. Түгәрәккә йөрүчеләрдән Бабыкина һәм Вотякова иптәшләр кырчылык бригадасына бригадир, Галова ферма мөдире итеп, стахановчы Левина колхоз хисапчысы итеп күтәрелделәр. Иптәш Голов колхоз председателе, Мигушин аның урынбасары булып сайландылар. Шулай ук түгәрәк членнарының иң алдынгылары ВКП(б) сафларына кабул ителделәр.

Агитколлектив инициативасы белән оештырылган түгәрәкләрдә катнашучылар колхоз производствосында гүзәл күрсәткечләр бирәләр. Мәсәлән, фермада эшләүчеләрдән Артемьева, Силагина, Куликова, Сапарина, Жаркова һ. б. иптәшләр һәрвакыт планнарын арттырып үтиләр. Меркулова, Левина һәм Вотякова иптәшләр ашлык сугуда нормаларын системалы рәвештә арттырып үтәделәр.

Бу колхоз район күләмендә авыл хуҗалыгы эшләрен алдынгылар сафында төгәлләде.

Билгеле, бу әле башлангыч уңышлар гына. Киләчәктә, большевистик агитация тагын да көчәйтелергә, аның гүзәл нәтиҗәләре тагын да күбрәк булырга тиеш.

Н. МОЛОДКИНА,

ВКП(б) ның Алексеевский райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире.

КОМСОМОЛ ОЕШМАСЫ ҮСӘ

Соңгы вакытларда комсомолның башлангыч оешмалары, союздан тыш яшьләр арасында политик тәрбия эшләрен шактый җәелдерделәр. Союздан тыш яшьләр комсомолның ачык җыелышларында катнашалар. Алар белән беседалар, кычкырып газета укулар үткәрелә. Берничә урында комсомолның устав-программасын өйрәнү түгәрәкләре эшли.

Бу чараларның практик нәтиҗәләре дә күренә башлады инде. Ноябрь аенда гына да, район буенча, алдынгы яшьләрдән 60 ка якын кеше комсомол сафларына кабул ителде. Декабрь аенда ВЛКСМ ның район комитеты бюросы утырышында да комсомол сафларына тагын 51 кеше алынды.

Р. ХӘСӘНОВА,

Норлат районы.

ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ ЯХШЫРТЫРГА КИРӘК

Биектау районы үзәгендәге предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә 5 комсомол оешмасы бар. Алар 30 комсомолецны берләштерәләр. Ләкин бу оешмаларның берсе дә үзенең эшен Ватан сугышы шартлары таләп иткән югарылыкта оештырмаган. Менә райсоюз янындагы оешманы алыйк. Бу оешманың секретаре иптәш Марахтанова үзендә бернинди дә җаваплылык сизми. Шуның нәтиҗәсендә комсомол оешмасы бернәрсә дә эшләми. 7-8 айдан бирле комсомол җыелышлары да булганы юк. Комсомолецлар 6 шар ай буена членлык взнослары түләмәгәннәр.

Хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитеты янындагы комсомол оешмасы да (секретаре иптәш Стрелец) бернәрсә дә эшләми. Бу оешмада 10 комсомолец учетта тора. Ләкин алар производствода да һәм җәмәгать эшләрендә дә алдынгылык рольне уйнамыйлар. Район элемтә бүлеге, халык суды янындагы комсомол оешмаларында да шул ук хәл.

Ләкин шунсы гаҗәп. Район үзәгендәге комсомол оешмалары эшенең шундый җимерелү хәленә килеп җитүенә ВЛКСМ ның район комитеты да һәм башлангыч партоешмалар да бер чара да күрмиләр. Бу хәл тиз төзәтелергә тиеш.

Д. СКВОРЦОВ.

КОМСОМОЛЕЦЛАР ИНИЦИАТИВАСЫ

Теләче районының «Марс №2» колхозы комсомолецлары, союздан тыш яшьләр белән берлектә, тагын бер патриотик инициатива күрсәттеләр. Алар, атларны язгы чәчүгә әзерләү эшенә шефлык итүне үз өсләренә алдылар.

Ат абзарларын җылыту, азыкларның саклануы, ат көчләреннән дөрес файдалану, яшь атларны тәрбияләү һәм сбруйларның әзерлеге мәсьәләсен тикшерделәр. Бу чараларны үткәрүдә ветврач, ат караучылар һәм колхоз активистлары катнаштылар.

Тикшерү нәтиҗәсе комсомол җыелышларында һәм колхоз идарәсе утырышында тикшерелде. Җитешсезлекләрне бетерү өчен практик чаралар билгеләнде. Икенче көнне комсомолецлар союздан тыш яшьләр һәм укучылар белән берлектә ат абзарларын җылыту буенча өмә үткәрделәр. Яшь атлар һәм колыннар өчен аеруча җылы һәм чиста урыннар әзерләнде. Атларны дөрес ашату тәртибе кертелде.

Яшь тайларны тәрбияләп, аларны язгы чәчү вакытында эшкә катнаштырырлык итеп өлгертү турында комсомолецларның йөкләмәләрендә аеруча зур урын бирелгән, ә колыннарны тәрбияләп үстерүне пионерлар, мәктәп балалары үз өсләренә алдылар.

Шулай ук, колхозда хәзер зоотехника укулары оештырылды. Анда комсомолецлар, союздан тыш яшьләр һәм колхоз активистлары катнашалар.

«Марс №2» колхозы комсомолецлары атларны язгы чәчүгә яхшы итеп әзерләү буенча шефлык итүне үз өсләренә алып, республикабызның барлык комсомолецларын, союздан тыш яшьләрен, пионерларын һәм мәктәп укучыларын социалистик ярышка чакырдылар.

ВЛКСМ ның Өлкә Комитеты бюросы бу инициативаны яхшы дип тапты.

...ЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫН ЯҢА ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК!

КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫ ЭШЛӘП ЧЫГАРУНЫ ТАГЫН ДА КӨЧӘЙТЕРГӘ

ЧИСТАЙ КАЗАННЫ ЯРЫШКА ЧАКЫРА

Бөек Ватан сугышы фронтларында тәмам җиңүгә ирешүне тәэмин итү, гитлерчы бандитларны тар-мар итү өчен Кызыл Армиягә коралларны һәм сугыш припасларын, азык продуктларын торган саен күбрәк бирергә кирәк. Ләкин шуның белән бергә, тылда фронт өчен корал коючы эшчеләргә, ашлык җитештерүче колхозчыларга һәм фронт өчен эшләүче барлык хезмәт ияләренә киң куллану товарларын да күбрәк һәм күбрәк бирергә кирәк. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган социалистик ярышта бу мәсьәлә җитди урыннарның берсен алып торырга тиеш.

Чистай шәһәре бу өлкәдә гүзәл инициатива күрсәтте. Анда, 8 нче январьда, партия, хуҗалык, профсоюз активы җыелышы булып үтте. Җыелышта төп мәсьәлә итеп, шәһәрдә киң куллану товарлары эшләп чыгаруны тагын да күтәрү мәсьәләсе тикшерелде.

Чистай предприятиеләрендә һәм артельләрендә киң куллану товарлары эшләп чыгару планы узган елның 4 нче кварталында 112 процентка, декабрь ае планы—118 процентка үтәлгән. Ләкин моның белән канәгатьләнеп калу дөрес булмас иде. Шәһәрнең мөмкинлекләре бик күп. Алардан тулысынча файдаланырга кирәк. 1943 нче елда киң куллану товарларын тагын да күбрәк эшләп чыгару өчен большевистик көрәшне киң җәелдерергә кирәк.

Актив җыелышы, Кызыл Армиянең 25 еллыгын зур уңышлар белән каршы алу, бу бөек дата хөрмәтенә социалистик ярышны җәелдерү турында 172 нче завод коллективы мөрәҗәгатен тикшергәннән соң, киң куллану товарларын эшләп чыгару буенча конкрет йөкләмәләр алды һәм Казан шәһәре предприятиеләрен һәм артельләрен ярышка чакырды.

Чистайлылар үз өсләренә түбәндәге йөкләмәләрне алалар:

Шушы елның 1 нче кварталында киң куллану товарлары эшләп чыгаруны, узган елның 4 нче кварталы белән чатыштырганда, 27 процентка арттырырга.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә 3,5 миллион сумлык күләмдә продукция эшләп чыгарырга.

Дефицитлы чимал һәм материаллар урынына алмаштыргычлар куллануны киңрәк һәм тулырак оештырырга (кондитер әйберләре өчен мальтоза патокасы җитештерү һәм производствода куллану, сабын кайнатуда каустик сода урынына поташ куллану, күн аяк киеме, тегү, агач эшкәртү кебек производстволарның калдыкларыннан күн төймәләр, агач мундштуклар, тараклар, балалар өчен аяк киемнәре, йорт хуҗалыгы әйберләре, бияләйләр эшләп чыгаруны киң оештыру һ. б.).

Шәһәрнең барлык предприятиеләрендә һәм артельләрендә производство расходларын 5—7 процент күләмендә киметергә.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә шәһәрдә яңадан 25 мастерской ачарга.

Шәһәрнең барлык предприятиеләре һәм артельләре каршында ярдәмче хуҗалыклар булдырырга, булганнарын киңәйтергә, аларда язгы чәчүгә әзерлек эшләрен (кырга тирес ташу, ашлама өчен көл җыю, авыл хуҗалыгы инвентарьларын ремонтлау, кирәк булган күләмдә орлык әзерләп кую һ. б. кебек эшләрне) 1 нче квартал ахырына кадәр төгәлләргә.

Алынган йөкләмәләрнең үрнәк төстә үтәлүен тәэмин итү өчен эшчеләр арасында масса-агитация эшләрен киң җәелдерергә, барлык эшчеләрнең индивидуаль ярыш договорлары белән чолганып алынуына ирешергә, алынган йөкләмәләрнең үтәлешен системалы рәвештә тикшерергә, ярыш алдынгыларын киң популярлаштырырга һ. б.

Бу йөкләмәләр актив җыелышында тикшерелгәннән соң бер тавыштан кабул ителде. Шәһәрнең барлык предприятиеләре, артельләре, аларның аерым цехлары, бригадалары, шул нигездә конкрет йөкләмәләр алып, ярыш договорлары төзеделәр.

Җыелышта кабул ителгән бу ярыш йөкләмәләренә ВКП(б) ның шәһәр комитеты секретаре Сидаев, шәһәр башкарма комитеты председателе Тверякова, заводның киң куллану товарлары эшләп чыгару цехы стахановчысы Матвейчик, мебель фабрикасы стахановчысы Зуева, промкомбинат стахановчысы Нюренберг, «Путь» артеленең итекләр эшләү цехы мөдире Хәйдәров, ит комбинатының утиль цехы бригадиры Гаянова, «Коваль» артеле стахановчысы Машкина һ. б. иптәшләр, барлыгы 33 кеше кул куйган.

«Казан шәһәре предприятиеләренең, артельләренең эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженер-техник работникларына мөрәҗәгать итеп без,—диләр алар үзләренең социалистик йөкләмәләрендә һәм хатларында,—Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган социалистик ярышка кушылырга, киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча партия һәм хөкүмәт тарафыннан безнең алдыбызга куелган бурычларны бергәләп намус белән үтәргә чакырабыз».

Аларның бу чакырулары казанлылар тарафыннан, һичшиксез, бердәм рәвештә кабул ителер һәм халык өчен киң куллану товарларын тагын да күбрәк эшләп чыгару буенча ике шәһәр ярышы киң колач алып җәелеп китәр.

ЯҢА ЦЕХЛАР ЭШКӘ КЕРЕШТЕЛӘР

Шушы көннәрдә генә «Кызыл Масра»» промартеле (Арча районы) янында яңа производство бүлекләре ачылды. Киез итек басу, тире иләү, мех сугу, чыпта сугу цехлары үзләренең эшләрен башлап җибәрделәр дә инде. Берничә көн эчендә 50 пар киез итек басылды, 100 метрга якын мех сугылды һәм 200 данә тире иләнде.

Җирле чималдан киң куллану әйберләре җитештерү өчен оештырылган бу цехларның эшләрен киң җәелдерү чаралары күрелә.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

Норлат районы «Большевик» колхозының иң яхшы ат караучысы иптәш Камалиев.
К. Тахтеев фотосы.

ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТ

АРЧА МТМ ы РЕМОНТКА ТОТКАРЛЫК ЯСЫЙ

БАЛТАЧ, 14 январь. **(Телефон буенча).** Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт турында Саба МТС коллективы мөрәҗәгатен тикшергәч, Балтач МТС эшчеләре тракторларга һәм аларга тагылма барлык машиналарга ремонт ясауны Кызыл Армиябезнең 25 еллыгы көненә—23 нче февральгә тәмамлау һәм эшне бары тик отлично билгесенә генә үтәү, ремонтның үзенә төшү бәясен шактый кимету, запас частьларга һәм ремонт материалларына шактый экономия ясау турында йөкләмә алганнар иде.

Коллективның гомуми йөкләмәсеннән чыгып һәрбер бригадага һәм ремонтта эшләүче һәрбер эшчегә аерым заданиеләр җиткерелде. Эшчеләр үзара социалистик ярыш договорлары төзеп, җиң сызганып эшкә керештеләр. МТС ның үз мастерскоенда башкарыла алмаслык катлаулырак эшләр (моторларга ремонт ясау, коеп эшләнә торган эшләр) ике арада төзелгән хуҗалык договоры буенча Арча МТМ ына йөкләтелде һәм МТМ бу эшләрне договорда күрсәтелгәнчә һичбер тоткарсыз үтәп баруны өстенә алды.

Башта эш яхшы гына барды. Ләкин озак та үтмәде, эшнең срогында үтәлүенә Арча МТС дирекциясе тоткарлык ясый башлады. Нәтиҗәдә, Балтач МТС ы 10 нчы январьда 27 трактор урынына бары 15 тракторны гына ремонттан чыгара алды. Арча МТС дирекциясенә бу турыда язма рәвештә дә һәм телдән дә берничә тапкыр белдерүләр ясалса да һаман үзгәреш юк. МТС та Арча МТМ ыннан моторлар һәм башка күп кенә детальләр кайтып җитмәү аркасында, күп кенә тракторлар ремонттан чыга алмый яталар.

МТС та авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт яхшы гына бара. 38 чәчү машинасының 28 е, 38 [illegible] 27 се ремонттан чыкты инде. Сабаннарга ремонт тә[illegible]

Стахановчылар, нинди генә тоткарлыклар булуга да карамастан, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 23 нче февральгә тәмамлау өчен бөтен көчләрен биреп тырышып эшлиләр. Тимерчеләрдән Гарәфи иптәш Исмагыйлов һәм Сибгат иптәш Мусиннар көнлек нормаларны 200—300 процентка үтәп, бик күпләргә яхшы үрнәк күрсәтәләр.

РЕМОНТ АКРЫН БАРА

ЮГАРЫ ОСЛАН, 14 январь. **(Телефон буенча).** Макыл МТС ында тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау бик акрын бара. Ремонтка керешкәнгә байтак вакыт узды инде. Ләкин әле 14 кенә трактор ремонттан чыгарылган. Төзәтелгән авыл хуҗалыгы машиналарының да саны бик аз.

МТС та эш узел системасында алып барыла. Ләкин узел-бригадалар арасында хезмәт дисциплинасының түбән булуы һәм кирәкле ремонт материаллары белән вакытында тәэмин ителмәү сәбәпле көндәлек нормаларның үтәлеше ифрат түбән. МТС җитәкчеләре ремонт мастерскоен запас частьлар белән тәэмин итүне һәм МТС ның үзендәге мөмкинлекләрдән файдалануны оештыру чараларын күрмиләр.

Аерым частьларны реставрацияләү бригадасы МТС та яхшы эшләүче бригадалардан санала. Бу бригаданы кирәкле ремонт материаллары белән тәэмин итеп, аңа эшлекле ярдәм күрсәтелсә, башка узелларда запас частьлар җитешмәүдән эштә тоткарлык булмас иде. МТС дирекциясе бу мәсьәләгә әһәмият бирергә тиеш.

ТАНКЛАР ТӨЗҮГӘ

Чуар Абдул (Тымытык районы) авыл советына караган колхозларның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү өчен средство туплауга зур активлык белән катнаштылар. Кыска гына вакыт эчендә колхозчылардан 150 мең сум акча җыелды. Киров исемендәге колхозның колхозчыларыннан 51 мең сум, «Завет Ильича» колхозы колхозчыларыннан 33 мең сум акча тупланды. «Завет Ильича» колхозы члены иптәш Кузьмин танклар колоннасы төзү фондына 2 мең сум, Ялантау колхозы члены иптәш Хәбиров 1.700 сум акча керттеләр.

Танклар колоннасы төзү фондына средство туплау дәвам итә.

Ш. ВӘЛИЕВ.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (Үзәк фронт). Н-че часть политбүлеге, дошман окопларына листовкалар ташлау буенча зур эш башкара. Рәсемдә: сугышка кадәр Ленинград университетының доценты булып эшләгән өлкән лейтенант П. Никитин үзе конструкцияләгән мортиркадан дошман окопларына листовкалар ташлый.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

14 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

14 нче январьда безнең гаскәрләр **Төньяк Кавказда**, һөҗүмне дәвам иттереп; район үзәге **Суворовскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Гражданский 1 нчесе, Ново - Сумженскаяны, Судниковскоены** һәм тимер юл станциясе **Суворовскаяны** алдылар.

Донның түбән агымы районында һәм Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

13 нче январьда Сталинград районында дошманның 26 транспорт самолеты юк ителде.

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары дошманның көчле рәвештә ныгытылган каршылык күрсәтү узелын алдылар. 32 ДЗОТ һәм блиндаж җимертелде һәм кулга төшерелде. 600 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 7 орудие, 24 пулемет һәм башка трофейләр кулга төшерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта безнең частьлар, алга таба барып, халык яши торган 6 пунктны алдылар. 1.000 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 22 танкысы һәм 2 бронемашинасы яндырылды һәм җимертелде. Икенче бер участокта дошман танкларының һәм пехотасының зур бер группировкасы, шуннан алда бик күп югалтуларга дучар ителгән булса да, контратакаларын туктатмады. Безнең пехотабыз, артиллеристларыбыз һәм танкистларыбыз немецларның контратакаларын кире кайтаралар һәм аларның техникасын һәм җанлы көчләрен кыралар. Халык яши торган бер пункт районында гына да немецларның 9 танкысы яндырылды.

* * *

Үзәк фронтта, Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак, безнең гаскәрләр дошман пехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар алып бардылар. Безнең частьлар гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм 300 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. 3 орудие, пулеметлар, автоматлар, винтовкалар һәм төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. 50 кеше пленг алынды.

Төньяк Кавказда безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы рәвештә алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть немецларның контратакасын кире кайтарды һәм бер тимер юл станциясенә бәреп керде. Кыска гына бик каты сугыштан соң совет сугышчылары станцияне гитлерчылардан чистарттылар. Дошман, үтерелгән хәлдә генә дә 400 солдатын һәм офицерын югалтты. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта совет танкистлары дошманның сугышчан сафлары аркылы үтеп чыктылар һәм немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр.

* * *

Украина партизаннарының бер отряды немецлар подразделениесенә каршы бик каты сугышта 50 гитлерчыны кырып ташлаган. Совет патриотлары, 79 снаряды белән берлектә бер орудие, эре калибрлы 2 пулемет, 2 станоклы пулемет, 19.000 патрон, 2 радиостанция һәм һәртөрле күп сугыш снаряженииләре кулга төшергәннәр. Берничә көн үткәч бу отрядның партизаннары бер тимер-юл күперен шартлатканнар һәм берничә урында элемтә линиясен өзгәннәр.

* * *

Зимовники шәһәре кешеләре, шулай ук Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары немец-фашист бандитларның ерткычлыклары турында акт төзеделәр. Актта болай диелә: «Зимовники өчен булган сугышлар вакытында кечерәк бер группа разведчик кызылармеецлар шәһәр читенә барып чыктылар. Берничә кызылармеец яраланды һәм гитлерчылар тарафыннан плен алынды. Немецлар яралы кызылармеецларны Рожкова йортына куып кертеп, аларны бик озак газапладылар, ә соңыннан тимер юлга өстерәп алып чыктылар һәм атып үтерделәр. Атылганнар арасында бер саннтарка да бар иде. Зимовники шәһәрендә гитлерчылар эшләгән җинаятьләр совет хәрби пленныйларын һәм хәтта коралсыз медицина работникларын немец - фашист кабахәтләренең кырулырында дәвам итүләрен тагын бер кат раслыйлар». Актка Зимовники шәһәр кешеләреннән И. Бондаренко, И. Рожкова, 2 нче ранг хәрби врач В. Алексеев, майор Н. Полторaков, капитан И. Лебедев, кызылармеецлар И. Моисеенко, Т. Болон һәм П. Иващенколар кул куйды.

* * *

13 нче январьда Германия информация бюросы түбәндәге хәбәрне тапшырды: «Кавказда руслар, бик нык алга киткән танклар берләшмәсе ярдәме белән, Минеральные Воды шәһәренә атака ясарга маташтылар. Танкка каршы ата торган аз гына сандагы орудиеләр ярдәме белән бик нык оборонада торган бер сапер берләшмәсенең кискен хәрәкәтләре нәтиҗәсендә дошманның шәһәргә һөҗүм ясарга маташуы кире кайтарылды... Совет гаскәрләренең калдыклары көнчыгышка таба еракка алып ташландылар». Баштарак Берлин лыгырдыклары Кызыл Армиянең Төньяк Кавказдагы һөҗүме турында гомумән бернәрсә дә дәшмәскә маташтылар. Хәтта алар, Кавказда немец гаскәрләре бер-бер артлы уңышка ирешәләр дип ышандырырга тырыштылар. Соңыннан гитлерчылар, Кавказда тәмам тынычлык, анда немецлар армиясе бары тик «фронтны гына тигезли» дип белдерделәр һәм кинәт, Германия халкының башына таш төшкән кебек, яңалык килеп чыга—совет гаскәрләре Минеральные Воды шәһәренә атака ясаганнар имеш! Немецлар командованиесе тарата торган бу кеше ышанмаслык әкият гитлерчы идарәчеләр даирәләрендә хөкем сөрә торган каушауны тагын бер кат күрсәтә.

Һәркемгә билгеле, совет гаскәрләре Минеральные Водыга барып җитүдән элек, сугыша-сугыша 170—200 километр үттеләр һәм күп кенә шәһәрләрне һәм халык яши торган пунктларны алдылар. Аннан соң совет гаскәрләренең Минеральные Воды шәһәрен һәм тимер юл узелын 11 нче январьда ук алганлыклары билгеле. Һәркемгә мәгълүм, Кызыл Армия частьлары, немец гаскәрләренең каршылык күрсәтүен җиңеп Минеральные Водыдан көнбатышка таба тагын берничә дистә километр алга киттеләр.

Германиянең информация бюросы мәгънәсез һәм ахмакларча ялганлый!

ГИТЛЕРЧЫЛАР СОВЕТ ПАРТИЗАННАРЫННАН КУРКАЛАР

СТОКҺОЛЬМ, 13 январь. (ТАСС). Немец фашист оккупантлар үзләре басып алган совет районнарында партизаннар хәрәкәтенең үсүеннән борчылуга төшкәннәр. Гитлерчыларның «Гамбургер Фремденблат» газетасы совет партизаннарының «мәкерле» булуларыннан, урманлы районнарда аеруча уңышлы хәрәкәт итүләреннән зарланып яза. Газета, немец гаскәрләренә үзләре булган урында бик нык разведка үткәрергә туры килә, ди. Партизаннарга каршы көрәшү өчен немецлар махсус «куркынычсызлык полициясе» төзергә мәҗбүр булганнар. Гитлерчылар газетасы партизаннар арасында бик яхшы атучы снайперлар бик күп икәнлекне һәм шунлыктан аларга каршы көрәшү өчен сыналган кешеләр кирәклекне әйтә. Газета партизаннар отрядларының, радио ярдәме белән, үзара элемтә тотуларын күрсәтеп үтә.

Аннары бу газета немец солдатларының еш кына партизаннар тарафыннан үтерелүләрен һәм партизаннарның күперләрне җимерүләрен һәм поездларны шартлатуларын хәбәр итә.

Гитлерчыларның «Националь цейтунг» исемле икенче бер газетасы оккупацияләнгән районнардагы халыкны партизаннарга булышлык итүдә гаепли. Газетаның әйтүенчә, совет партизаннары Германия гаскәрләренә һәм бигрәк тә аларның тылдагы коммуникацияләренә каршы чын сугыш хәрәкәтләре алып баралар. Газета партизаннарга каршы көрәшнең кыенлыкларыннан зарлана һәм партизаннарның кеше үтә алмаслык урманнарда да үзләренә сыенып урын табуларын әйтеп үтә.

ИТАЛИЯДӘ ҖИМЕРЕКЛЕК

ИСТАМБУЛ, 13 январь. (ТАСС). «Пополо д' Италиа» газетасының икърар итүенчә, тимер юл транспортының чыгырыннан чыгуы һәм транспорт средстволарының җитешмәве аркасында Италиянең төньягындагы шәһәрләрдән халыкны оешкан төстә күчерергә мөмкин түгел. Газета: «Безгә халыкны күчерү өчен бик күп өстәмә транспорт средстволары кирәк, ләкин алар юк»,—дип яза. Йөз меңнәрчә итальяннар, үзләренең барлык милекләрен ташлап, җәяүләп күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

«Стампа» газетасының язуына караганда, Турин шәһәре властьларының аерым кешеләр кулындагы автомобиль транспортына реквизиция ясаулары да халыкны күчерү эшендәге кыенлыкларны йомшартмаган. Ягулыкка кризис булганлыктан транспортның чыгырыннан чыгуы тагын да арта. Шулай ук ягулыкның җитешмәве Италиянең бөтен промышленностена да йогынты ясый. Шул ук газетаның язуынча, ягулык кризисы нәтиҗәсендә үткән елның ноябреннан башлап 70 ләп предприятие үзләренең эшләрен бөтенләй туктатканнар.

Италия властьлары бомбага тотудан җимерелгән промышленность предприятиеләрен аякка бастыра башларга тырышып караганнар, ләкин төзү материаллары булмауга килеп терәлгәннәр.

Италия матбугаты Италиядә азык ягыннан кискен кыенлыклар барлыкны күрсәтә. Гаять күп азыкның Германиягә чыгарылуы һәм Италиянең үзендә Германия гаскәрләрен ашату, «Стампа» газетасының икърар итүенчә, «Италия халкын азык белән тәэмин итүгә начар йогынты ясый».

ТРИПОЛИТАНИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 13 январь. (ТАСС). Англиянең Якын Көнчыгыштагы кораллы көчләре командованиесенең белдерүендә әйтелүенчә, кичә Англия самолетлары Триполитаниядәге сугышлар районы турысында дошманның 5 истребителен атып төшергәннәр.

12 нче январьга каршы төндә Англия бомбардировщиклары Триполины һәм Хомсны, ә 12 нче январьда Крит, Сицилия һәм Лампедуза атауларындагы объектларны бомбага тотканнар.

Марокко радиосының хәбәр итүенә караганда, Вади-Зәмзәм районында Англиянең алгы частьлары урнашкан урынга шактый күп ярдәмче көчләр килгән. Шулар арасында бик күп танклар да бар.

Шуның өстенә, Марокко радиосының хәбәренчә, кичә төштән соң 8 нче армия патрульләре Вади-Зәмзәм турысында дошман позицияләре районында бик актив хәрәкәтләр алып барганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 13 январь. (ТАСС). Америка Кушма Штатларының хәрби информация бюросы Америка самолетларының 11 нче январьда Триполитаниядәге Кастель Бенитоны бомбага тотканлыкларын хәбәр итә.

ЛОНДОН, 13 январь. (ТАСС). Англиянең Якын Көнчыгыштагы көчләре командованиесенең белдерүендә Триполитания фронтында дошман авиациясенең активлыгы кечәйгәнлеге әйтелә. 11 нче январьга каршы төндә Англия авиациясе Триполи белән Мисурата арасындагы юлда дошман объектларын бомбага тоткан. Сус гаванена һәм Габес белән Сфакс арасындагы юлдан баручы дошман транспортына уңышлы һөҗүм ясалган. 11 нче январьда көндез союзниклар самолетлары Неапольга һөҗүм иткәннәр.

ЭЛЬЗАС ХАЛКЫ БУЙСЫНДЫРЫЛМАГАН

ЛОНДОН, 13 январь. (ТАСС). АФИ агентлыгының хәбәр итүенчә, Эльзаста хәлләр элеккечә киеренке. Эльзасны немецлар басып алганнан соң Гитлерның наместнигы Вагнер эльзаслыларга мөрәҗәгать итеп, «Без беләбез, сез безне яратмыйсыз, ләкин без сезне бездән куркырга мәҗбүр итәрбез», дигән. Оккупация властьларының барлык чараларына эльзаслыларның каршылык күрсәтүенә җавап итеп, немецлар террорны көчәйтәләр. Йөз меңнәрчә эльзаслылар йортларыннан куып чыгарылганнар һәм билгесез якка озатылганнар. Ләкин оккупантлар эльзаслыларның азатлык сөю рухын сындыра алмаганнар. Моны Гитлер сатрапы Вагнер үзенең соңгы речендә икърар итте. Ул болай диде: «Без зур рәхимсезлек күрсәттек, ләкин безнең алдыбызда әле һаман да буйсынмаган халыкны буйсындыру бурычы тора».

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 13 январь. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы гаскәрләре штабының хәбәр итүенә караганда, француз гаскәрләре Пон-Дю-Фастан 37 километр көньяктарак булган тау аралыгын алганнар. Союзникларның истребительләре Тунис яры турысында дошманның 3 транспорт самолетын бәреп төшергәннәр. Союзниклар самолетларының кичерәк бер берләшмәсе дошманның Габес якынындагы объектларын бомбага тоткан. Шулай ук Триполитаниядәге Гадамеска да һөҗүм ясалган.

Немецлар Фондуктан 8 километр көньяктарак француз частьларына каршы көчле атака ясаганнар, ләкин авыр югалтуларга дучар булып чигенгәннәр.

Җаваплы редактор урынбасары

ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген—„*Манең улым*“, 16 нчы январьда — „*Фельдмаршал Кутузов*“. Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Татар дәүләт филармониясе. Менжинский исемендәге клубта бүген һәм 16 нчы, 17 нче январьда — *Молдавия дәүләт джазының соңгы гастрольләре.* Кич 8 сәгатьтә башлана.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген—„*Мәрьям*“ Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Дәүләт циркы. Бүген *чегән ансамбле* белән *зур цирк тамашасы*“. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 16 нчы январьда—„*Ильдар*“.

„Электро“ — Америка фильмы—„*Сиңа сокландым*“.

„Унион“—„*Алтмыш тугызынчы параллель*“.

„Пионер“ көндез—„*Конек-Горбунок*“, кич—„*Георгий Саакадзе*“.

„Чаткы“ — „*Корыч ничек чыныкты*“.

„Кызыл йолдыз“ — „*Гроза*“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27. редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ. 614 „КРАСНАЯ ТАТАРИЯ“ һәм „КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН“ издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 81.